ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2017елның «22» мартыннан № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»02.11.2010 №880 карарына таянып, «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге 535 номерлы Башкарма комитет карарына ярашлы рәвештә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.Агачларны һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең беркетелгән административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны «Лениногорские вести» рәсми публикатор-газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, гражданнарны күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Б. Табаков

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72